КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1280

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карары белән расланган Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 303 нче, 2013 ел, 20 август, 585 нче, 2015 ел, 29 сентябрь, 725 нче, 2015 ел, 13 октябрь, 763 нче; 2016 ел, 26 август, 595 нче; 2018 ел, 22 август, 684 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Агентлык үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә товар базарларында көндәшлекне үстерү максатларының һәм бурычларның өстенлеген тәэмин итә.»;

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү һәм социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин